| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.03. 2019 ел Баулы шәһәре №66

**Баулы муниципаль районында милек һәм җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 2018 елның 27 июлендә кабул ителгән 210-ФЗ номерлы Федераль закон (2018 елның 29 июлендәге редакциядә) нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендә кабул ителгән 880нче номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»гы карарына таянып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1нче кушымта);

1.2. Җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен территорияләрнең кадастр планында урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2нче кушымта);

1.3. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген даими (срогы чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3нче кушымта);

1.4. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милекчелеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4нче кушымта);

1.16. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга бакчачылык алып бару өчен милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (16нчы кушымта);

1.17. Шәхси яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядән (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башка категориягә күчерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (17нче кушымта);

1.18. Җир кишәрлегеннән даими (сроксыз) файдалану хокукын яки җир кишәрлегеннән гомерлек мирас итеп файдалану хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (18нче кушымта);

1.19. Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (19нчы кушымта);

1.20. Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (20нче кушымта);

1.21. Җир кишәрлекләрен бушлай милеккә алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламент (21нче кушымта);

1.22. Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут билгеләү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (22нче кушымта);

1.23. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга индивидуаль торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (23нче кушымта);

1.24. Муниципаль торак фондыннан торак урыннарын гражданнарга милеккә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (24нче кушымта);

1.25. Элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (25нче кушымта);

1.26. Муниципаль милекне муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында рәсмиләштерү (беркетү)

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров